СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д. 13, д.Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 13 йорты, Урта Курса
авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366)53-4-32, факс (84366)53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**карары**

**« 06» май 2024 ел** **№ 76**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 22 декабрендәге 78 номерлы Урта Курса авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 №83, 08.11.2019 № 102, 20.02.2020 № 107, 14.08.2020 № 116, 08.12.2020 № 10, 16.07.2021 № 13, 28.03.2023 №55 үзгәрешләр белән)**

"Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында" Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 23.03.2024 №54-ФЗ, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 79 статьясына һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законның 28_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 23.03.2024 N54-ФЗ, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 02.03.2007 № 25-ФЗ федераль законнар нигезендә, Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 22 декабрендәге 78 номерлы Урта Курса авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 №83, 08.11.2019 № 102, 20.02.2020 № 107, 14.08.2020 № 116, 08.12.2020 № 10, 16.07.2021 № 13, 28.03.2023 №55 үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктча белән тулыландырырга:

«12) әлеге Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).»;

2) 10.1 пунктның 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узган вакытта аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган ялган документлар һәм (яки) билгеле ялган мәгълүматлар яисә алар муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү турында таныклый торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны тапшырмау;»;

3) 12.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.5. Мәнфәгатьләр каршылыгы ягы булган муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып торган мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

4) 12.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.7. Үзенә буйсынган яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу чаралары буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

5) 15.3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета»;

6) 15.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.4. Әлеге Федераль закон нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлары (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Кайбер муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән мәгълүматны тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.»;

7) 20.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.7. Муниципаль хезмәткәрләргә үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, мәгълүмат бирү мәҗбүри булган очракта, яки тулы булмаган мәгълүмат бирү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

8) Түбәндәге эчтәлектәге 20.7.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«20.7.1. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора».

9) Түбәндәге эчтәлектәге 20.1. бүлек белән тулыландырырга:

«20.1. Анкета тапшыру, анкетада булган мәгълүмат үзгәрү турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү.

1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тапшыра.

2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итә.

3. Анкета формасы, шул исәптән аңа кертелә торган белешмәләрнең исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

4. Анкетадагы белешмәләр яллаучы (эш бирүче) вәкиленең яисә ул вәкаләт биргән затның карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетадагы белешмәләрне тикшерү гавами хакимият органнарына һәм тиешле мәгълүматка ия оешмаларга, язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә җибәрү юлы белән, муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла. Тиешле мәгълүматка ия гавами хакимият органнары һәм оешмалар соратып алына торган мәгълүматны әлеге гариза алынган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.»;

10) 30.11. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30.11. Муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

11) Түбәндәге эчтәлектәге 30.11.1 пунктча белән тулыландырырга:

«30.11.1. Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән формада керүне рәсмиләштерү;».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070